**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 14 маендагы 8-38 номерлы карары**

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә иҗтимагый-җитештерү объектларын (ОП) (12 номерлы контур) урнаштыруның территориаль зонасы һәм мохиткә тискәре йогынтысы аз булган җитештерү-коммуналь объектлар (П2) (9 номерлы контур) зонасы чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 20 статьясы нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 11 февралендәге 330 номерлы «Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыруның территориаль зонасы (ОП) (12 номерлы контур) һәм мохиткә тискәре йогынтысы аз булган җитештерү-коммуналь объектлар зонасы (П2) (9 номерлы контур) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында Казан шәһәре Думасы карары проектын әзерләү хакында»гы карарын һәм 2025 елның 3 апреленнән 2025 елның 24 апреленә кадәр уздырылган җәмәгатьчелек белән фикер алышулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Казан шәһәре Думасы **карар бирде:**

1. Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында, әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә, территориаль зона – мохиткә тискәре йогынтысы аз булган җитештерү-коммуналь объектлар зонасы (П2) (9 номерлы контур) чикләренә Крутовка урамы буенча урнашкан 16:50:080110:71, 16:50:080110:72 кадастр номерлы җир кишәрлекләрен кертеп, территориаль зона – иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру зонасы (ОП) (12 номерлы контур) чикләрен үзгәртергә;

1.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән территориаль зоналарның үзгәрә торган чикләрен Кагыйдәләр составында шәһәр төзелешен зоналаштыруның түбәндәге карталарында чагылдырырга:

- шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы;

- территориаль зоналарның урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында;

- территориаль зоналарның территорияне югары интенсивлыкта файдалану, шәһәр төзелешендә әһәмияткә ия территорияләр ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: тарихи җирлек ярдәмче зонасы күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында;

- чикләрендә территорияләрне комплекслы үстерүне гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территорияләр картасы;

1.3. Кагыйдәләргә 1 номерлы кушымтаны әлеге карарга 2 номерлы кушымта (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) нигезендә территориаль зоналар чикләре урнашу урынының график тасвирламасы белән тулыландырырга;


1.4. Кагыйдәләрнең 2 номерлы кушымтасына әлеге карарның 3 номерлы кушымтасы нигезендә территориаль зоналар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеген (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) өстәргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 14 маендагы
8-38 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты**




**ОП - 12**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы

**Территориаль зона**

| Төс | Индекс | Территориаль зона төренең атамасы |
|---|---|---|
| | ОП | Иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру зонасы |
| | П2 | Мохиткә тискәре йогынтысы аз булган җитештерү-коммуналь объектлар зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты чикләре |

**Башлыкның беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**